**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге Советы**

# Карар

**05 ноябрь 2019 ел** **№ 188**

**Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 ноябрендә кабул ителгән 192 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 ноябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» гы 192 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 2015 нче елның 11 сентябрендә № 239, 2018 нче елның 29 октябрендә № 147, 2019 нчы елның 21 мартында № 170 кабул ителгән карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктның өченче абзацында «һәм салым ташламасына хокукны раслаучы документлар» сүзләрен «шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** **И.Р. Вәлиев**